Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XLV-3**

Балык Бистәсе штп. 2019 елның 24 сентябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2011 елның 18 февралендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль казна учреждениеләре турында” IX-2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13.3 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2011 елның 18 февралендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль казна учреждениеләре турында” IX-2 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2014 елның 10 гыйнварындагы XXXIV-2 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-мәдәни өлкә бүлеге” муниципаль казна учреждениесе турында Нигезләмәне түбәндәге эчтәлекле “Мәнфәгатьләр конфликтын (низагын) булдырмау һәм җайга салу” 7.[1] бүлеге белән тулыландырырга:

“7.[1] Мәнфәгатьләр конфликтын (каршылыгын) булдырмау һәм җайга салу”

7.1.1. Мәнфәгатьләр каршылыгы дигәннән хезмәткәрнең шәхси кызыксынуы булган шундый вәзгыять аңлашыла, андый вакытта аның хезмәт бурычларын тиешенчә үтәвенә йогынты ясарга мөмкин һәм шул ук вакытта ул хезмәткәрнең шәхси кызыксынуы һәм хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре арасындагы каршылык барлыкка килергә яки туарга мөмкин, бүлек хезмәткәре булган бүлекчәнең мөлкәтенә һәм (яисә) эшлекле абруена зыян китерергә сәләтле.

7.1.2. Хезмәттәге бурычларын тиешенчә үтәүгә йогынты ясый яисә йогынты ясый ала торган бүлек хезмәткәренең шәхсән кызыксынуы дигәннән хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә акча, кыйммәтләр әйберләр, башка мөлкәт рәвешендә керемнәр алу мөмкинлеге аңлашыла, шул исәптән үзе өчен яисә өченче затлар өчен мөлкәти хокуклар, яисә мөлкәти характердагы хезмәт күрсәтүләр.

7.1.3. Бүлек җитәкчесе эш бирүчегә вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итәргә тиеш.

7.14. Бүлек хезмәткәре вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китергән яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында бүлек башлыгына хәбәр итәргә тиеш. Бүлек башлыгына хәбәр итү тәртибе, хәбәрнамәләрдә булган мәгълүматлар исемлеге, әлеге мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм хәбәрнамәләрне теркәү тәртибе Бүлек башлыгы тарафыннан билгеләнә.”;

1.2) “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге” муниципаль казна учреждениесе турында Нигезләмәне түбәндәге эчтәлекле “Мәнфәгатьләр конфликтын (низагын) булдырмау һәм җайга салу” 7.[1] бүлеге белән тулыландырырга:

“7.[1] Мәнфәгатьләр конфликтын (каршылыгын) булдырмау һәм җайга салу”

7.1.1. Мәнфәгатьләр каршылыгы дигәннән хезмәткәрнең шәхси кызыксынуы булган шундый вәзгыять аңлашыла, андый вакытта аның хезмәт бурычларын тиешенчә үтәвенә йогынты ясарга мөмкин һәм шул ук вакытта ул хезмәткәрнең шәхси кызыксынуы һәм хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре арасындагы каршылык барлыкка килергә яки туарга мөмкин, бүлек хезмәткәре булган бүлекчәнең мөлкәтенә һәм (яисә) эшлекле абруена зыян китерергә сәләтле.

7.1.2. Хезмәттәге бурычларын тиешенчә үтәүгә йогынты ясый яисә йогынты ясый ала торган бүлек хезмәткәренең шәхсән кызыксынуы дигәннән хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә акча, кыйммәтләр әйберләр, башка мөлкәт рәвешендә керемнәр алу мөмкинлеге аңлашыла, шул исәптән үзе өчен яисә өченче затлар өчен мөлкәти хокуклар, яисә мөлкәти характердагы хезмәт күрсәтүләр.

7.1.3. Бүлек башлыгы эш бирүчегә вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итәргә тиеш.

7.14. Бүлек хезмәткәре вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китергән яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында бүлек башлыгына хәбәр итәргә тиеш. Бүлек башлыгына хәбәр итү тәртибе, хәбәрнамәләрдә булган мәгълүматлар исемлеге, әлеге мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм хәбәрнамәләрне теркәү тәртибе Бүлек башлыгы тарафыннан билгеләнә.”;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Л. Ислановка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык  Бистәсе муниципаль район
Башлыгы                                                                                    И.Р. Таҗетдинов